# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

## КАРАР
IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2020 елның 16 декабре № 24 Урыссу ш.т.п.

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Мактау тактасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактау тактасын гамәлгә куярга.
2. 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактау тактасы турындагы нигезләмәне расларга.
3. 2 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Мактау тактасында урнаштыру өчен кандидатларны раслау буенча комиссия төзергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы районы Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Кушымта №1
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы
Карарына
2020 елның 16 декабреннән
№__24__

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Мактау тактасы турында НИГЕЗЛӘМӘ**

1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы Мактау тактасы (алга таба – Мактау тактасы) Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын (алга таба - гражданын), алар арасында өлкәннәр дә, яшьләр дә булырга мөмкин, аларның эштәге, спорттагы, укудагы казанышлары, иҗтимагый-файдалы эшчәнлекләре өчен бүләкләү рәвешләренең берсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының (алга таба - муниципаль район) социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән, алар граждан җаваплылыгы, хезмәт сөючәнлеге, гаилә традицияләренә, ана һәм ата бурычларына тугрылык үрнәге булып торган гражданнарны бүләкләү формасы буларак гамәлгә куелган.

1.2. Мактау тактасына урнаштырылырга хокуклы булып һөнәри, хезмәт, җәмәгать эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешкән гражданнар, шулай ук муниципаль районның социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән гражданнар санала.

1.3. Мактау тактасы «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе бинасында түбәндәге адрес буенча урнаштырыла: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Урыссу ш.т.п., Урыссу ур., 60 йорт, карау өчен уңайлы урында.

1.4. Мактау тактасы, дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә): “Доска почета” «Мактау тактасы» дип рус һәм татар телләрендә язылган Ютазы муниципаль районы гербы урнашкан үзәк панельдән тора, А4 форматындагы фотосурәтләр өчен өске рәттә - 4 рам һәм үзәк рәттә 8 рам, аскы рәттә 8 рам була. Мактау тактасының гомуми озынлыгы 2,20 метр, ә биеклеге 1,20 метр тәшкил итә.

1.5. Гражданнарны Мактау тактасына урнаштыру турында таныклыклар Татарстан Республикасы Ютазы районының оешуы көненә багышланган чараларда тапшырыла.

1.6. Гражданнарны Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатуралар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Мактау тактасында урнаштыру өчен кандидатларны раслау комиссиясе тарафыннан (алга таба - район комиссиясе) карала һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана (алга таба - район Башлыгы).

1.7. Фотосурәтләр Мактау тактасына 1 елга урнаштырыла.

## 2. МАКТАУ ТАКТАСЫНА УРНАШТЫРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ АНЫ ДОКУМЕНТАЛЬ РӘСМИЛӘШТЕРҮ

2.1. Мактау тактасына урнаштырылуга һөнәри, хезмәт, җәмәгать эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешкән гражданнар, шулай ук муниципаль районның социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән гражданнар кандидатуралары тәкъдим ителә.

2.2. Бер кандидатны Мактау тактасына урнаштыру турында тәкъдим белән ел саен җирле үзидарә органнары, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре, индивидуаль эшкуарлар (алга таба - Гариза бирүче) мөрәҗәгать итә ала.

2.3. Мактау тактасына кертү турындагы мәсьәләне хәл итү буенча тәкъдимне Мөрәҗәгать итүче район Башлыгына түбәндәге материалларны теркәп җибәрә: үтенечнамә, аның кандидатурасын Мактау тактасына кую турында кандидатның ризалыгын һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта), кандидатның биографиясен, кандидатның һөнәри, хезмәт, иҗтимагый эшчәнлегенең югары нәтиҗәләре турында бәяләмәне, гомуми җыелыш беркетмәсеннән (оешма әгъзаларыннан) кандидатны күрсәтү турында өземтәне, кандидатның фотопортретын.

Үтенечнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта):

- Гариза бирүченең төгәл исеме (кайсы ведомствога каравын һәм почта адресын күрсәтеп);
- кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм эш (уку) урыны;
- кандидатны Мактау тактасына урнаштыру турындагы тәкъдимнең нигезләү формулировкасы;
- коллегиаль орган тарафыннан күрсәтелгәндә - коллегиаль орган әгъзалары саны, тавыш бирүдә катнашучылар саны, тавыш бирү нәтиҗәләре.

2.3.2. Кандидатның биографиясендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме (паспорт нигезендә);
- туган датасы, ае, туган елы;
- соңгы эш урыны, вазыйфасы;
- гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме;
- хезмәт һәм өй адреслары (почта индексларын күрсәтеп) һәм телефоннар;

паспорт мәгълүматлары (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән, яшәү урыны буенча теркәлү).

2.3.3. Бәяләмә-характеристикада кандидатның һөнәри, хезмәт эшчәнлеге һәм иҗтимагый эшчәнлеге, күренекле казанышлары турында ышандырырлык белешмәләр булырга тиеш.

2.3.4. Тәкъдим ителгән барлык материалларга Гариза бирүче имза салырга тиеш.

2.3.5. Үтәлеп бетмәгән хөкем карары булган, шулай ук барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр буенча бурычлары булган затлар, хезмәт хакын түләү буенча бурычлары булган затлар Почет тактасына урнаштыру өчен тәкъдим ителә алмый.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән барлык материаллар район Башлыгына агымдагы елның 1 мартыннан 15 маена кадәр тапшырылырга тиеш.

2.5. Кергән материаллар район комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иҗтимагый советы вәкилләрен чакыртып карала. Гражданнарны Мактау тактасына кертүгә тәкъдим итү турындагы карар утырышта катнашкан комиссия әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән һәр кандидатура буенча аерым-аерым кабул ителә һәм район Башлыгы раславына кертелә.

2.6. Мактау тактасына урнаштыру турында кабул ителгән карар «Ютазы таңы» газетасында басылырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
Кабул ителгән карар нигезендә Мактау тактасына фотога төшерү өчен расланган гражданнарны фотога төшерү эшләре башкарыла.

2.8. Мактау тактасына кертелгән гражданнар гариза бирүченең карары буенча акчалата премияләр яки кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнәләр.

2.9. Әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән гражданнарны Мактау тактасына кертү турындагы махсус таныклыкны рәсмиләштерү, үтенечнамәләрне исәпкә алу һәм теркәүне Татарстан Республикасы Ютазы район Советының оештыру бүлеге гамәлгә ашыра. Мактау тактасына кертелү турында махсус таныклыкның рәвеше әлеге Нигезләмә (әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта) белән раслана.

2.10. Таныклыклар бланкларын рәсмиләштерүгә, Мактау тактасына төсле фотопортретлар өчен рамнар ясауга, шулай ук Мактау тактасын тиешле дәрәҗәдә тотуга агымдагы чыгымнар тиешле рәвештә муниципаль район бюджетында исәпкә алына.

2.11. Гражданның фотосурәте район Башлыгы карары белән вакытыннан алда гражданинның намусын һәм абруен төшерә торган гамәлләр кылган өчен, шулай ук законлы көченә кергән суд карары нигезендә җинаять кылган өчен Мактау тактасыннан алына.

Кушымта №1
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Мактау тактасы турындагы
НИГЕЗЛӘМӘГӘ

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә**
**РИЗАЛЫК**

Мин,
_______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
________________________________________________________________
____________________________________________сериясе
№____________
(шәхесен таныклый торган документ төре)
бирелгән
_____________________________________________________________,
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
адресы буенча яшәүче ________________________________
________________________________________________________________
__,
Татарстан Республикасы Ютазы район Советының минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүенә үземнең ризалыгымны бирәм һәм, мондый ризалыкны биргәндә, мин үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә эш итүемне раслыйм.

Килешү минем тарафтан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактау тактасына фотосурәтемне урнаштыру максатыннан бирелә һәм түбәндәге мәгълүматларга кагыла:

- фотосурәт;
- фамилиям, исемем, атамның исеме;
- вазыйфа һәм эш урыны;
- яшәү урыны адресы;
- паспорт мәгълүматлары.

Шулай ук минем шәхси мәгълүматларым:

- фотосурәт;
- фамилиям, исемем, атамның исеме;
- вазыйфам һәм эш урыным -

һәркемгә мәгълүм булырлык шәхси мәгълүматлар булып тора.

Әлеге ризалык, югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәкле яисә теләгән шәхси мәгълүматларыма карата төрле гамәлләрне гамәлгә ашыруга бирелә, шул исәптән, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), куллануны, таратуны (шул исәптән тапшыруны), зарарсызландыруны, юкка чыгаруны, шәхси мәгълүматларны читкә тапшыруны, шулай ук федераль законнарны исәпкә алып, минем шәхси мәгълүматларым белән теләсә нинди гамәлләрне башкаруны күздә тота.

Мин биргән шәхси мәгълүматлардан хокуксыз файдаланган очракта, минем язма белдерүем белән ризалык кире алына.

Әлеге ризалык 20____ елның "___"___________ нән гамәлдә.

____________________________________

__________________________

(ризалык биргән затның фамилиясе, инициаллары) - (имза)

"____"_________ 20______ ел

Кушымта №2
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Мактау тактасы турындагы
НИГЕЗЛӘМӘГӘ

**Ютазы муниципаль районы Мактау тактасына урнаштыру турында ҮТЕНЕЧНАМӘ**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме __________________________________

2.Туу датасы____________________________________________

3. Вазыйфасы, эш урыны ____________________________________________ ________________________________________________________________.

4. Белеме (уку йортының исеме, тәмамлау елы) ____________________________________________________________________

.5.Гомуми эш стажы __________________________________________________.

6.Тармакта эш стажы______________________________________________.

7.Әлеге вазифада әлеге предприятиедә, оешмада, учреждениедә эш стажы ____________________________________________________________

8. Нинди дәүләт, ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән, бүләкләү даталары, карар (боерык) номеры _______________________ __________________________________________________________________.

9. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының нинди бүләкләре белән бүләкләнгән, бүләкләү даталары, карар номеры _____________________________________ __________________________________________________________________.

10. Мактау тактасында чагылдырылырга тиешле күрсәткечләр:

| |
|---|
| Ф.И.А.и. (тулысынча)<br>Үтенечнамә биргән предприятие, учреждение,<br>оешманың тулы исеме |

Учреждение, оешма, предприятие җитәкчесе имза
Ф.И.А.и.
М.У.

Профком рәисе имза
Ф.И.А.и.
М.У.

Кушымта №3
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы
Мактау тактасы турындагы
НИГЕЗЛӘМӘГӘ

ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-80-13, факс:2-62-20, e-mail: jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www. jutaza.tatarstan.ru

______________№____________
На № _________от____________

ТАНЫКЛЫК
№ _______________ ___________
20__ елда
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Мактау тактасына урнаштыру турында

_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының һәрьяклап үсешенә ярдәм иткән саллы өлеше өчен.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы имза Инициаллар, Фамилия

Кушымта №2
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советының
2020 елның 16 декабреннән
Карарына
№__24___

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатлар раслау комиссиясе СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе** | |
| Шәфигуллин А. Ә. | Татарстанның Ютазы муниципаль районы Башлыгы |
| **Комиссия рәисе урынбасары** | |
| Самонина С. П. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| **Комиссия секретаре** | |
| Майорова Н.В. | Татарстан Республикасы Ютазы район Советы аппараты җитәкчесе |
| **Ведомствоара комиссия әгъзалары** | |
| Ильясов З.В. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы урынбасары |
| Галиев С.Ә. | 2 нче санлы Бәйрәкә сайлау округыннан депутат |
| Нәбиуллин Р.М. | 9 нчы санлы Байлар сайлау округы депутаты |
| Лукин Н.В. | 9 нчы санлы Яссытугай сайлау округы депутаты |
| Хисмәтуллин Р.В. | Урыссу ш.т.п. №10 Техснаб сайлау округы депутаты |
| Г. В. Кубашева | №7 Әбсәләм сайлау округы депутаты |
| Әминова Ф.Г. | №4 Иске Урыссу сайлау округы депутаты |
| Рузанов С.А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасары (килешү буенча) |